СОВЕТ ОРЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422629 д. Орел,
ул. Олимпийская, д.2а
тел: 4-49-10

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ОРЕЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422629 Орел поселыгы,
Олимпия урамы, 2 а нчы йорт,
тел: 4-49-10

2024 елның 6 сентябре 126 номер

КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Орел авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмә хакында» Орел авыл җирлеге Советының 2023 елның 25 гыйнварындагы 72 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024елның 08 августындагы 289-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Орел авыл җирлеге советы, КАРАР ИТТЕ:

1.«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Орел авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмә хакында» Орел авыл җирлеге Советының 2023 елның 25 гыйнварындагы 72 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә, түбәндәге редакциядә бәян итеп:

4.6.4. пункт. Планнан тыш күчмә тикшерү бары тик прокуратура органнары белән килештереп кенә үткәрелергә мөмкин, моңа 57 статьяның 1 өлешендәге 3 - 5 пунктлары һәм 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә уздыру очраклары керми.

4.9.5. пункт. Күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында каралган карар кабул ителә алмый.

4.7.10 Пункт. Рейд тикшерүе прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа 248 - ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3-5 пунктлары һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12_1 өлешләре нигезендә үткәрелгән очраклар керми

2.Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3.Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Орел**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Фетилина В.И**